**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР №3**

Акбаш ав. 17.01.2015

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Акбаш авыл җирлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салымын җыю**
**һәм алардан файдалану тәртибе турындагы**
**нигезләмәне раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 56 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 75 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең 2005 елның 12 ноябрендә кабул ителгән Акбаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге гражданнарының үзара салым турындагы 8 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 адресы буенча һәм Ютазы муниципаль районының рәсми интернет сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.М.Миннеханов

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Акбаш авыл җирлегенең
2015 елның 17 гыйнварындагы
3 санлы карарына
1 санлы кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Ютазы муниципаль районы**
**Акбаш авыл җирлеге территориясендә**
**гражданнарның үзара салымын җыю**
**һәм алардан файдалану тәртибе турындагы**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге (алга таба - авыл җирлеге) территориясендә җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен халыкның өстәмә акчаларын җәлеп итү, җыю һәм куллану тәртибен җайга сала.

2.1. Яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары.

Гражданнарның үзара салым акчасы астында гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган бер тапкыр бирелә торган түләүләре аңлашыла.

Гражданнарның үзара салымы мәсьәләсе буенча җирле референдум – гамәлдәге законнар, җирлек уставы нигезендә җирлек чикләрендә яшәү урыны буенча теркәлгән Россия Федерациясе гражданнары арасында үзара салым мәсьәләсе буенча яшерен тавыш бирүдә гражданнарның гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыярын белдерү нигезендә үткәрелә торган референдум.

## 2. Гражданнарның үзара салымы мәсьәләсе буенча референдум үткәрү турында инициативаны тәкъдим итү

2.1. Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә.

2.2. Гражданнарның үзара салым мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән:

- җирле референдумда катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнарына;

устав сайлауларда һәм (яки) референдумнарда катнашуны күздә тоткан, федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәсенә, башка иҗтимагый берләшмәгә;

- авыл җирлеге Советына һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенә, алар тарафыннан бергәләп тәкъдим ителгән.

## 3. Җирле референдумны билгеләү, әзерләү һәм үткәрү

3.1. Җирле референдум билгеләү турындагы карар җирлек Советына җирле референдум билгеләнә торган документлар кергән көннән 30 көн эчендә җирлек Советы тарафыннан кабул ителә.

3.2. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе 2004 елның 24 мартындагы «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы белән җайга салына.

3.3. Җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү белән бәйле чыгымнарны финанслау җирлек бюджеты акчалары хисабына башкарыла.

## 4. Җирле референдум карары

4.1. Гражданнарның үзара салымы җирле референдумда кабул ителгән карар буенча җирлек территориясендә кертелә.

4.2. Референдум үзара салым буенча түләүләр күләмен һәм җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне раслый, аларны хәл итүгә җыелган акчалар тотыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, аерым категорияләрдән тыш, җирлекнең барлык гражданнары өчен абсолют зурлыкта билгеләнә.

4.3. Тавыш бирү нәтиҗәләре һәм җирле референдумда кабул ителгән карар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларын урнаштыру юлы белән Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт адресы буенча һәм Ютазы муниципаль районының рәсми интернет-сайтында мәҗбүри хәбәр ителергә тиеш. Җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми рәвештә халыкка җиткерелгәннән соң үз көченә керә.

4.4. Үзара салым билгеләү турында референдум карары җирлекнең барлык гражданнары өчен мәҗбүри булып тора.

## 5. Үзара салым акчаларын җыю тәртибе

5.1. Гражданнарның үзара салым акчалары референдум нәтиҗәләре игълан ителгәннән соң ике ай дәвамында, яшәү урыны җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләргә карамастан, җирлек чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән барлык гражданнар, референдум карары буенча ташламалы категория дип танылган гражданнардан тыш, җирлек башкарма комитетының банк реквизитларын үз эченә алган хәбәрнамәсе нигезендә, җирлек башкарма комитеты хәбәренә, шулай ук түләү тәртибе турында мәгълүматка нигезләнеп башкарыла.

5.2. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар җирлек Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

5.3. Түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп - хисап ясау хокукына ия оешмалар (алга таба-исәп-хисап оешмалары), җирлек башкарма комитеты кассасы аша, терминаллар яки Интернет челтәре аша башкарыла.

5.4. Түләү фактын раслый торган касса ордерының квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар.

## 6. Үзара салым акчаларын куллану

6.1. Үзара салым тәртибендә җыелган һәм әлеге Нигезләмәнең 5.1 пункты нигезендә җирлек бюджетына кергән акчалар җирле референдумда кабул ителгән карарда каралган җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне (конкрет мәсьәлә) хәл итүгә җирлек башкарма комитеты тарафыннан тотыла.

6.2. Җирлек башкарма комитеты референдумда кабул ителгән карар үз көченә кергән көннән җиде көн эчендә референдум карарын тормышка ашыру максатыннан чаралар планын раслый.

6.3. Хисап елында файдаланылмаган акчалар киләсе финанс елына күчә һәм референдум карары белән каралган максатларга тотыла.

6.4. Җирлек башлыгы елга бер тапкыр җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлеше турында җирлек халкы алдында хисап тота.

6.5. 6.4 пункты нигезендә әзерләнгән авыл җирлеге башлыгының отчетлары. әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларын урнаштыру юлы белән Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 адресы буенча һәм Ютазы муниципаль районының рәсми интернет сайтында игълан ителә.

6.6. Үзара салым акчаларын дөрес исәпләүне, тулысынча һәм үз вакытында түләүне тикшереп торуны җирлек башкарма комитеты башкара.

## 7. Әлеге Нигезләмәне бозган өчен җаваплылык

7.1. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салымы акчалары федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

7.2. Акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Контроль-хисап палатасы тарафыннан башкарыла.